وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+


# Дин вә Мәгыйшәт

№9 (178). 1 март 2013 / 19-рабыгыль-ахир-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Вакыф төшенчәсе һәм аның асылы ▷2,4◁



Дин әһеле (имамнар) сөйләме үзенчәлекләре ▷3◁



Нәфис чәчәк сулмасын иде ▷4◁

## АВЫРЛЫКЛАРДАН СОҢ ҖИҢЕЛЛЕК КИЛЕР

*"Дөреслектә, файдалы булган җиңеллек авырлыктан соң" ("Инширах (Ачмак)" сүрәсенең 5 нче аяте).*

**Әлеге тирән мәгънәле аять яшәешнең мәгънәсен аңларга ярдәм итә. Авырлыкларсыз яшәп булмый, һәрберебез җир йөзендә сынаулар аша үтә. Авырлыклар төрле булырга мөмкин: ачлык яки мохтаҗлык кына түгел. Мәсәлән, кем өчендер гафу үтенү авыр. Аңа авыр, ләкин гафу үтенгәч, ул җиңеллек кичерә. Кемдер яңа эш башлап җибәрергә курка, ләкин башлагач, илһам ала, чөнки һәр дөрес эштә кешегә дәрт-дәрман бирерлек искиткеч зур энергия бар.**



Кеше табигате һәм Аллаһы Тәгалә яралткан һәрбер нәрсә бу аятьнең дөреслеген дәлилли. Бар табигать сулган көздән соң һәм салкын кыштан соң бөтен җирне яңартып, яз һәм кояшлы җәй килә, яңгырдан соң салават күпере чыга, буран тынгач, тынлык урнаша. Яз - кеше һәм табигать яңарыш кичергән матур вакыт. Шул ук вакытта җаннарыбыз да яңарырга, начарлыкларны онытып, яхшылыкка омтылырга - тән һәм җан сәламәтлеген какшатучы үпкәләүләрне онытырга, гафу итәргә, нәтиҗәләре начар булган гамәлләрнең тәҗрибәсен алып, яңа яхшы гамәлләр кылырга тиеш. Яңару... Яз - активлык, күтәренкелек вакытына күчүне гәүдәләндерә, бу безгә Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә вәгъдә иткән җиңеллеккә өмет бирә.

Чыннан да, уйлана белгән кеше бар нәрсәдә дә Аллаһы Тәгалә биргән билгеләрне күрә һәм бу билгеләрне яхшы итеп аңлатып бирү аның үзеннән тора. Психология күзлегеннән караганда, һәр вакыйганың да уңай якларын таба белү кирәк. Бу тиз рәнҗи торган кешенең психикасын саклап калу өчен генә түгел, Аллаһы Тәгаләдән булган бөтен нәрсәне шөкер итеп кабул итәргә диган боерыкны үтәү өчен дә бик мөһим. "Җир һәм күкләрнең төзелешендә, төн белән көннең бер-берсенә каршы булуларында, кешеләргә кирәк нәрсәләрне күтәреп диңгезләрдә корабларның йөрүендә, күктән яңгыр яудырып, Аллаһы Тәгаләнең үлгән җирне тергезүендә, җир өстендә һәртөрле хайваннарны халык кылуында, җилне һәм җир белән күк арасында болытны йөртүендә, әлбәттә, Аллаһның барлыгына һәм берлегенә иман китерү өчен шиксез ачык дәлилләр бар" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 164 нче аяте).

Әгәр дә без Аллаһы Тәгаләгә генә инансак, үзгәрешләр, безгә башта нинди генә булып күренсәләр дә, һәрвакыт яхшыга гына булыр. Бу иманлы кешене башкалардан аерып тора.

"Дөреслектә, файдалы булган җиңеллек авырлыктан соң". Начарлыкны һәрвакыт яхшылык алыштыра. Бу - төшенкелеккә бирелүчән кешеләргә төп мөрәҗәгать. Бу - уйлану өчен дә бер сәбәп булып тора. Чөнки бу аять кешенең дөньяга карашын төптән үзгәртә һәм дөнья, һәм ахирәт өчен дә уңышка ирешергә омтылучан итә ала.

***Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## Бөгелмәдә мөнәҗәтләр фестивале үтте

**24 февраль көнне Бөгелмә шәһәрендә I Республикакүләм "Зәйтүнә" мөнәҗәтләр фестивале үткәрелде.**

"Мөнәҗәт" дигән сүз Аллаһка ялвару, Аңа мактау сүзләрен җиткерү дигәнне аңлата. Элек-электән үк халкыбыз өчен мөнәҗәтләр динебез кыйммәтләрен саклау чарасы булып торган. Иң авыр заманнарда да әбиләребез аларны көйләп юанган.

Республикабызда беренче тапкыр мөнәҗәтләр фестивален Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Бөгелмә районы мөхтәсибәте, Бөгелмә шәһәрендәге Татар мәдәният үзәге оештырды. Чара кысаларында узган конкурста Татарстанның төрле районнары – Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Зәй, Мамадыш һәм Казаннан килгән мөнәҗәтчеләр катнашты. Казан ислам колледжы һәм башкалабыздагы "Ак өмет" пансионаты шәкертләре дә үзләренең осталыкларын сынады.

Мөнәҗәт әйтү бәйгесенә мәртәбәле жюри әгъзалары – Татарстанның халык артисты, КФУ профессоры Миңгол Галиев, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые Марат хәзрәт Мәрданшин, Россия ислам институты мөгаллиме Ильяс Халиков, "Алтын урта" мөселман яшьләре оешмасы җитәкчесе Акйолдыз Фәйзова, мөнәҗәтләр башкаручы Римма Карамниса бәя бирде.

Балалар арасында җиңүче булып Ильяс Минһаҗев (Бөгелмә районы Карабаш бистәсе) танылды, II урын – Айдар Дәүләтгәрәевтә (Бөгелмә районы Иркен авылы) һәм III урынга шулай ук Карабаш бистәсеннән Розалина Рамазанова чыкты. 13-17 яшьлекләр арасында III урын – Тәлгать Сөләймановта (Казан), II урын – Резидә Габрахмановада (Бөгелмә), I урын Мамадыштан килгән Алсу Исрафиловада булды. Зурлардан III урынны Рәфис Шәйдуллин (Мамадыш), II урынны Алсу апа Нигъмәтуллина (Баулы) яулады, җиңүче булып Зәй шәһәреннән килгән Фатих Нуруллин танылды. Балалар ансамбльләреннән "Ак өмет" (Казан) – өченче, Сәет Давыт һәм Сәет Каман (Казан) – икенче, "Ишрак" (Бөгелмә) беренче булды. Зурлардан Бөгелмә Татар мәдәният үзәге "Мирас" төркеменә тиңнәр булмады, икенчелеккә Карабаштан "Тургай" ансамбле лаек булды, өченче урында – Казанның "Мәрҗани" төркеме. Фестивальнең Россия ислам институты студенты Сәет Давыт лаек дип табылды.

Җиңүчеләргә электрон китап, флешка, MP3-плеер, интернет-планшет, нетбук, фотоаппарат, видеокамера кебек кыйммәтле бүләкләр бирелде.

## ЯҢАЛЫКЛАР

### "САБЫЙГА" АКЦИЯСЕ БАШЛАНА

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Татар радиосы" һәм Бөгелмә мөхтәсибәте белән берлектә, әти-әниләре ташлаган сабыйларга подгузник, пелёнка кебек кирәк-яраклар җыю максатыннан, "Сабыйга" хәйрия акциясе уздыра.**

Сабыйлар Бөгелмә районы балалар хастаханәсе каршында урнашкан "социаль койкалар"да сәламәтләндерү һәм тернәкләндерү курслары үтәчәк. Мондый курсларны алар 30 көн эчендә үтеп бетәргә тиеш, ләкин тормыш күрсәткәнчә, әлеге вакыт аралыгында гына моңа ирешеп булмый, шунлыктан дәвалану берничә айга сузыла. Балаларны урнаштыру буенча аларның хокукларын кайгырту (опека) бүлеге шөгыльләнә, алар балага яңа әти-әни таба яки аны якындагы балалар йортына урнаштыру җаен карый. Уртача алганда, ай дәвамында балаларның "социаль койкалар"ыннан дистәгә якын сабый уза. Әлеге сабыйлар үзләренең әти-әниләре тарафыннан кире кагылсалар да, җир йөзендә ярдәм кулы сузарга әзер торучы мәрхәмәтле кешеләр аз түгел. Барчагызны да сабыйларның гомеренә битараф калмаска чакырабыз.

Акция 1 марттан 31 мартка кадәр узачак. Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр бала карау әйберләрен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә китерә ала. Адресыбыз: Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 йорт, хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге. Элемтә өчен телефон: +7 (843) 264-61-58 (Гөлнара Садыйкова).

### ГАБДУЛЛА ХӘЗРӘТ ЙОШКАР-ОЛАДА ЧЫГЫШ ЯСАДЫ

**27 февраль көнне Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов Марий Эл Республикасы башкаласында "Ислам террорлыкка каршы" дип аталган "түгәрәк өстәл"дә катнашты.** Чара Татар мәдәнияте үзәге, Йошкар-Ола шәһәре хакимиятенең мәдәният идарәсе белән берлектә үткәрелде.

"Түгәрәк өстәл"дә "Дини агымнар һәм төркемнәр"; "Россиядә ислам"; "Бүгенге җәмгыятьтә ислам төшенчәсе"; "Ислам һәм яшьләр" темасына караган мәсьәләләр күтәрелде.

### САБРИ ТУНЧ АНГЫЛЫ КАЗАН ИСЛАМ КОЛЛЕДЖЫНДА БУЛДЫ

**Төркиянең Казандагы генераль консулы сыйныфларны, китапханәне, ашханәне карады, шулай ук колледж студентлары өчен төзелә торган тулай торак төзелеше белән таныш-ты.** Казан ислам колледжы директоры Мансур хәзрәт Җәләлетдинов консулга уку йортының тарихы һәм үсеше турында сөйләде, уку һәм тәрбия процесслары белән таныштырды.

Исегезгә төшерәбез: бер ай элек Төркиянең Казандагы генераль консуллыгы колледжга 41 томлык "Ислам энциклопедиясе" (төрек телендә) бүләк иткән иде.

***Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Вакыф төшенчәсе һәм аның асылы



## Бетмәс-төкәнмәс хәйриячелек

Вакыф - хәләл максатлар өчен файдалануга бирелгән, аны тапшыручының, аның белән ниндидер сатып-алу, алмашу кебек хокуклары булмый торган, һичкайчан бетми һәм юкка чыкмый торган мөлкәт.

Вакыф шәригать тарафыннан хупланган һәм таләп ителгән гамәл булып исәпләнә. Андый төрдәге мөлкәтнең барлыкка килүе Коръән һәм Сөннәткә нигезләнә. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди:

لَنْ تَنَالُوا الْبِرَّ حَتَّى تُنْفِقُوا مِمَّا تُحِبُّونَ وَمَا تُنْفِقُوا مِنْ شَيْءٍ فَإِنَّ اللَّهَ بِهِ عَلِيمٌ

(Мәгънәсе): ***"Үзегезгә сөекле нәрсәләрдән мохтаҗ мөселманнарга бирмичә торып, Аллаһтан бирeләчәк рәхмәтләргә (ягъни җәннәткә керүгә) ирешә алмассыз. Бит Аллаһ сезнең нинди нәрсәләрдән сәдака биргәнегезне беләдер"***. ("Әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсенең 92 аяте).

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) сәхабәсе Әбу Талха (Аллаһ аңардан разый булса иде!) бу аятьне ишеткәч үзенең бар мөлкәтен дә Аллаһ юлына сарыф итәргә карар иткән. "Сахих әл-Бохари" җыентыгындагы хәдистә бу вакыйга турында шулай бәян ителә: "Әбу Талха (Аллаһ аңардан разый булса иде!) бу аятне ишеткәч Аллаһның Рәсүленә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) ашыккан, Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) бу аятне укып чыккан һәм болай дигән: "Минем иң зур мөлкәтем - Бараха (бакча исеме) һәм мин аны Аллаһ һәм Аның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) юлында тоту өчен бүләк итәм. Бу бакча белән Аллаһ кушканча гамәл кыл, миңа савабы булыр", - дигән. Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) аңа җавап итеп, шул вакытта: "Афәрин, Әбу Талха, табыш китерә торган бу мөлкәтне без синнән кабул итеп алдык һәм кире дә кайтарабыз: аны үз якыннарың һәм кардәшләреңә бир", - дигән. Һәм Әбу Талха аны үзенең якын туганнарына биргән".

*Әбу Һөрәйрә (Аллаһ аңардан разый булса иде!) Пәйгамбәрдән шундый хәдисне тапшырган: "Кеше вафат булганнан соң, аның өч төрле гамәленнән: ул бирeп калдырган бетми торган хәйриячелек мөлкәте, башкалар файдалану өчен ул калдырган белемнәр һәм аның үз ата-аналары өчен ялварып гыйбадәт кыла торган иманлы баласыннан тыш, аның бар эшчәнлеге дә туктаячак" (Мөслим, 1631).*

عن ابى هريرة ان رسول الله صلى الله عليه وقال إذا مات الانسان انقطع عنه عمله الا من ثلاثة الا من
صدقة جارية أو علم ينتفع به أو ولد صالح يدعو له

Мөселман галимнәре "бетми торган хәйриячелек" сүзләрен вакыф дип аңлаталар.

Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) сәхабәсе Гомәрнең улы Гомәр (Аллаһ аларның икесеннән дә разый булса иде!) шундый хәдисне тапшырган. Ул хәдистә болай дип сөйләнә: аның әтисе Гомәр (Аллаһ аңардан разый булса иде!) Хәйбәрне (Мәдинә янындагы бер урынны) яулаган вакытта ганимәт итеп җир биләмәсе алган. Бу җир биләмәсенә ия булгач, Гомәр (Аллаһ аңардан разый булса иде!), бу җир биләмәсе белән нишләргә дип киңәшләшү өчен, Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) килгән һәм Аллаһның Рәсүленә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) мөрәҗәгать иткән: "Ий Аллаһының Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!), минем өлешкә Хәйбәр янындагы җир биләмәсе тиде. Минем моңа кадәр әле бу җир биләмәсеннән дә кыйммәтрәк мөлкәткә ия булганым юк иде. Миңа бу җир биләмәсе белән ни кылырга киңәш итәсең?" Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) аңа: "Әгәр теләсәң, вакыф ит син аны", - дигән. Шуннан соң Гомәр (Аллаһ аңардан разый булса иде!) бу җир биләмәсен вакыф иткән. Тик шундый шарт куйган: аны сатарга да, бүләк итәргә дә, мираска калдырырга да тиеш түгелләр; аның белән мохтаҗлар, сугышта катнашучылар, кунаклар файдалансын, аны кулланып, колларга азатлык сатып алынсын. Бу җир белән файдаланып, аның биргәннәрен, чамасын белеп кенә (үзенә байлык туплау максатларында файдаланмыйча) кулланyда берниди дә гөнаһ юк". Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) сәхабәсе Гомәр (Аллаһ аңардан разый булса иде!) оештырган менә шул вакыф Ислам тарихында беренче вакыф булган да инде. Вакыфка бирү гадәте тиз арада мөселманнар арасында киң таралып ала. Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) сәхабәсе Җәбир (Аллаһ аңардан разый булса иде!): "Вакыф эшләргә чак кына булса да мөмкинлеге булган очракта, аны эшләми калган бер генә сәхабә дә юк иде", - дип әйтеп калдырган.

## Вакыфның зирәклеге

1) Аллаһка якынаю, күп савап алу. Һәр мөэминмөселман өчен, Аллаһы Тәгаләнең аңа булган сөюен арттыра торган, Аллаһка якын булу һәм савап алудан да сөеклерәк гамәл юк бит.

2) Үз мөлкәтеңне вакыф милке итү - Аллаһы Тәгалә алдында үзеңнең Аның колы булуыңны раслау, Аңа карата булган сөюеңне чагылдыру ул. Ә Аллаһы Тәгаләне сөю исә Аның күрсәтмәләре буенча гамәл кылудан да күбрәк, башка берниди гамәлдә дә чагылыш алмый.

3) Алда әйтеп кителгән хәдистәгечә, үзеңнән соң, хәтта үз вафатыңнан соң да савап китереп тора торган, бер дә бетми, киресенчә - дәвамлы, бетмәс-төкәнмәс саваплы хәйрия калдыру ул - вакыф эшләү.

4) Вакыф - мөселман җәмгыяте өчен бөек игелек эшләү дигән сүз. Чөнки бу вакыф мәчетләр, мөселман дини уку йортлары (мәдрәсәләр) төзү, гыйлем тарату кебек җәмгать максатларына сарыф ителәчәк.

5) Вакыф эшләү - ярлыларның, мөлкәтсез кешеләрнең, ятимнәрнең, мосафирларның һ. б. хаҗәтләрен үтәү ул.

## Вакыф арканнары (төп өлешләре)

Вакыфның дүрт төп өлеше бар: а) аны оештыручы [вакфу]; б) вакыфка, вакыф сыйфатында мирас итеп калдырылган мөлкәт; в) вакыфның мирас итеп калдырылучысы; г) вакыфның мәгънә асылы, билгеләмәсе.

## Вакыф оештыручыга булган таләпләр, шартлар:

1) Вакыф оештыручы сүзләренең юридик яктан чынлыгы. Ягъни вакыфны оештыручы балигъ булган, ирекле кеше булырга һәм ул акыл ягыннан зәгыйфь булмаска тиеш.

Вакыф өлешләренең һәрберсе, үз чиратында, үз шартларына ия. Кол вакыф оештыра алмый, чөнки аның үз мөлкәте юк, хәтта ул үзе дә үзенеке түгел, аңа башка кеше, аның хуҗасы хуҗа. Вакыфны балигълык яшенә җитмәгән яки акылына зыян килгән кеше, аны (аларны) тәрбиягә алучылар, аның янында булып һәм аларның рөхсәте белән булса да (аларга да, шулай ук мөлкәтнең ниндидер бер өлеше белән вакыф эшләү тыела), төзи алмый.

2) Оештыручы - хәйриячелек өчен хокуклы кеше булырга тиеш. Әгәр дә кемнең дә булса мөлкәтне тыелган чаралар белән табуы, яки сарыф итүе, яисә аның көрчеккә (банкротлыкка) чыгуы аркасында (ягъни аның күп бурычлары булуы аркасында) ул мөлкәтен куллануга тыю салынган икән, ул кешенең вакыф оештыру хокукы юк.

3) Ихтыярилык. Әгәр дә вакыф кем дә булса башка бер кешенең басымы, мәҗбүрләве нәтиҗәсендә төзелгән икән, ул чын вакыф булып санала алмый.

## Вакыфка мирас итеп калдырылучы мөлкәткә куелган таләпләр

Вакыфка мирас итеп калдырыла торган мөлкәт җисми булырга тиеш. Барлыкка килә торган файданы (табышны), ул файда (табыш) китерүче мөлкәтнең үзеннән тыш кына вакыф итеп кадыру рөхсәт ителми. Бу вакытта, вакыфның - ниндидер билгеле вакытка гына яки даими рәвештә бирелүенең - әһәмияте юк. Мәсәлән, кемнеңдер үз йортын яки фатирын яшәү өчен биреп торудан, вакытлыча яки даими килгән файданы (табышны) вакыф итеп тапшырып булмый. Вакыф, шул ук вакытта вакыф итеп бирелә торган мөлкәт тәгәл билгеләнмәгән булса да төзелә алмый. Мәсәлән, кем дә булса үзенең ике йортыныn берсен, аның кайсы икәнен тәгәл генә әйтмичә, вакыф итә икән, бу йорт вакыф булып кабул ителә алмый.

2) Мирас итеп калдырыла торган милек оештыручының үзенеке булырга тиеш һәм аның файда китерүе лазем. Әгәр кем дә булса үзенеке булмаган берәр мөлкәтне вакыф итеп тапшырган икән, андый вакыф гамәлгә ашмаган булып исәпләнә. Кеше үз-үзен дә вакыф итә алмый, чөнки ул үзенеке түгел, һәрбер инсан - Аллаһ бәндәсе. Шул ук вакытта, әгәр дә бу мал (терлек, җанвар) үзе вакыф ителмәгән икән, малның карынындагы яралгысын да вакыф итү мөмкин түгел. Без мәкальбез башында вакыф итеп китерелә торган мөлкәт ниндидер файда, табыш китерергә тиеш икәнлегеен әйтеп киткән идек инде. Мәсәлән, әгәр дә иген үстерергә, төзелешкә һәм башка максатларга да яраклы булмаган җирне яки тузган, таушалган киемне вакыф итеп тапшырганда, бу вакыф гамәлгә ашкан булып исәпләнә алмый, чөнки алардан берниди дә файда юк.

3) Вакыфка тапшырылган мөлкәттән килгән файда - дәвамлы булырга тиеш. Мәсәлән, азык-төлек кебек һәм шуңа охшаш башка, файдасы аның юкка чыгуы яисә бозылуы белән генә мөмкин булган әйберләр белән вакыф эшләү мөмкин түгел. Дәвамлылык дигән вакытта, файданың мәңге дәвам итүе күз алдында тотылмый, ә бу әйберне ниндидер билгеле бер вакытка куртымга (арендага) бирү мөмкинлеге күз алдында тотыла. Мәсәлән, машина яки ниндидер бер малны (терлекне) вакыфка биргәндә, бу вакыф булып исәпләнә, гәрчә машинадан килә торган файда даими булмаса да (машина ватылырга, эштән чыгарга һәм аңа зыян килергә мөмкин). Мал (терлек) турында да шуны ук әйтергә була. Вакыф итеп бирелгән мөлкәтнең тапшырылган мизгелендә үк файда китерүе мөһим түгел, вакыф киләчәктә файда китерә торган мөлкәт булса да чын вакыф булып исәпләнә. Мәсәлән, берәр яшь малны (терлекне) вакыф итеп китергәннәр икән, бу чын вакыф булып исәпләнә, чөнки киләчәктә бу малдан файда киләчәк.

4) Вакыфка тапшырылган мөлкәттән килгән файда рөхсәт ителгән (хәләл) булырга тиеш. Әгәр кем дә булса шәригать буенча тыелган ниндидер мөлкәтне вакыф итә икән, андый вакыф чынга саналмый.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Дин әһеле (имамнар) сөйләме үзенчәлекләре

**Вәгазь һәм нотык сөйләү һөнәре бик борынгы һөнәрләрдән санала. Мәшһүр гарәп вәзирләреннән берсе - Хәсән бине Сәһил заманында үз улларына мондый нәсихәт биргән: "Әй улларым! Нотык сөйләргә өйрәнегез! Кешенең хайваннан аермасы - аның сөйләшә белүедер. Нотыгыгыз камил булса, кешелегегез дә камил булыр!"**



Дөрестән дә, тел, сөйләшә алу мөмкинлеге адәм балаларына Яратучы тарафыннан бүләк ителгән зур нигъмәт. Телнең көченнән, сөйләм мөмкинлекләреннән гади халык та, төрле һөнәр ияләре дә файдалана. Төрле дәрәҗәдәге хәзрәтләр, муллалар, гомумән, дин әһелләре эшендә дә тел, сөйләм осталыгы төп корал булып санала. Әйтергә кирәк, ислам диненең таралуы да Аллаһ Раббыбызның соңгы пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәламнең хикмәтле, белемле, бик тә сабыр, әхлаклы булуы белән генә бәйле булмаган. Аның бай теле, искитмәле оратор булуы да гаять зур роль уйный.

Сүз көче, сөйләм осталыгы дин әһеле өчен ифрат зур әһәмияткә ия булуын исәпкә алып, мөселманнар бу мәсьәләгә һәрдаим зур игътибар биреп килгәннәр. Элеккеге мәдрәсәләрдә дә, бүгенге дини уку йортларында да вәгазь, хөтбә сөйләү серләре махсус дәресләрдә өйрәнелә. Шулай итеп, булачак имамнар, муллалар һәм мөгаллимнәр кешеләргә динне дөрес итеп аңлату, вәгазь сөйләү нечкәлекләрен, һичшиксез, үзләштерергә һәм хезмәтләрендә файдаланырга тиешләр.

***

Муллаларның, имамнарның сөйләм ысулларына килгәндә, түбәндәге үзенчәлекләрне билгеләп үтәргә мөмкин:

1) башка һөнәр ияләреннән аермалы буларак, дин әһеленең сөйләме үз эченә төрле дини терминнарны алырга тиеш; имамнарга Коръән аятьләрен дә, хәдисләрне дә урынлы куллану мәслихәт;

2) шул ук вакытта имам нотыгы гади һәм аңлаешлы булырга тиеш, чөнки аны тыңлаучы аудитория төрле яшьтәге, төрле белем дәрәҗәсенә ия булган тыңлаучылардан гыйбарәт. Моны, һичшиксез, исәпкә алырга кирәк;

3) нинди дә булса җәмәгать алдында чыгыш ясарга җыенган кеше сөйләргә ниятләгән текстның бербөтенлеген күз алдында тотып, сүз сөрешенең эзлеклелеген, мантыйкка (ягъни логикага) нигезләнгән булуын кайгырту лазем. Бу, әлбәттә, дин әһеле сөйләмендә дә игътибарга алынырга тиешле бик мөһим нәрсәләрнең берсе;

4) имам вәгазе композиция, ягъни төзелеше ягыннан алдан уйланылган, төгәл булырга тиеш. Беркайчан да халык алдына: "Әйдә ярар, нәрсә булса да сөйләрмен әле", - дип уйлап, чыгып басарга ярамый. Хәтта тәҗрибәле, телгә бай дин әһеле дә үз чыгышын алдан планлаштыра, берничә зур һәм кечкенәрәк кисәкләргә бүлә, һәр кисәкнең төп фикерләрен үзе өчен тәгаенләп куя.

Кереш өлештә, гадәттә, иң элек вәгазьнең темасы билгеләнә, аннары аның әһәмияте, бүгенге актуальлеге ассызыклана, аерым шәхес һәм тулаем җәмгыять тормышына ясаган йогынтысы турында әйтелә. Боларны ачыклаучы һәр фикер, һәр җөмлә аңлаешлы, анык һәм төгәл булырга тиеш. Кереш өлештә вәгазьче тышкы, ягъни тыңлаучыларга ишеттерелә торган, һәм эчке, ягъни башкаларга әйтелмичә, шәхсән үзе өчен генә тәгаенләнә торган бурычлар һәм максатлар билгеләргә тиеш. Вәгазьнең җиткерү рәвеше, тулаем сыйфаты нәкъ менә шул бурыч-максатларга бәйле.

Төп өлештә теманың асылы ачыла. Бу өлешне ике зур кисәккә бүлү мәслихәт. Беренче кисәк, гадәттә, теоретик рухта булып, сайлап алынган теманы гомуми тасвирлауга багышлана. Биредә темага (проблемага) кагылышлы мәгълүмат бирелә, Коръән аятьләре, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) хәдисләре, галимнәрнең фикерләре китерелә. Икенче кисәктә теманы практик яктан - тарихтан һәм бүгенге тормыштан алынган мисаллар ярдәмендә ачыклап, шушы мәсьәләне белүнең, дин, шәригать буенча аның ничек хәл ителүен аңлауның файдалары турында сөйләргә мөмкин.

Вәгазьнең йомгак бүлеге нәтиҗә чыгаруга багышлана. Биредә барлык сөйләгәннәр гомумиләштерелеп, вәгазьче тыңлаучыларга әйтәсе килгән төп фикерне җиткерә. Нәтиҗә ясалганда, фикер сөреше төзек, җөмләләр төгәл һәм аңлаешлы булырга тиеш. Йомгакта әйтелгән төп фикернең кереш өлештә билгеләнгән бурычлар белән бәйле булуы мөһим.

Нәтиҗәне бәян итүнең берничә төре бар. Шуларның берсе - фикерләрне номерлап, ягъни "беренчедән", "икенчедән" дип тезеп китү. Бу уңайлы, фикерне конкретлаштырырга ярдәм итә торган вариант. Нәтиҗә ясауның башка - ирекле, вәгазьченең уйлануларын үз эченә ала торган төрләре дә бар. Шулай да, дин әһеле ясаган нәтиҗәдә Аллаһның бөеклеге, Аның чиксез Кодрәте һәм олуг Рәхмәте хакында, һичшиксез, әйтелергә тиеш. Тормышыбыздагы һәр вакыйга, һәр мәсьәлә Аллаһ Раббыбызның Хикмәте белән нурландырылган булуы турында искәртү бик мөһим. Имам алдына куелырга тиешле максатлардан тагын берсе - мәсьәләнең тирән тамырлары хакында белдереп, аның асылына төшендереп, алган гыйлемне тормышта кулланырга өндәү;

5) вәгазь сөйләүчегә чыгышның вакыты турында да онытмаска кирәк: ул бик озакка сузылса, җәмәгатьнең игътибары сүрелә башларга, шул сәбәпле сөйләүчегә карата кызыксыну югалырга мөмкин. Шул ук вакытта вәгазьне бик кыска тоту, беренчедән, тыңлаучыларга карата ихтирамсызлык буларак бәяләнүе ихтимал, икенчедән, вәгазь темасын берничә минут эчендә генә яхшы ачыклап булмый;

6) имам үзенә һәм сөйләгән темасына игътибар җәлеп итү өчен яхшы хикәяләүче (рассказчик) сыйфатларына да ия булырга кирәк. Коръәннән, борынгы тарихтан алынган кызыклы риваятьләр сөйләү, хәзерге реаль тормыштан гыйбрәтле мисаллар китерү вәгазьне баета, имам сөйләмен тере, мавыктыргыч итә;

7) вәгазь сөйләүчегә хас булырга тиеш тагын бер үзенчәлек - ул сөйләмнең образлы булуы. Бу үзенчәлек турыдан-туры хикәяләүче сыйфаты белән бәйле. Фикерне дөньяви һәм дини мәгънәдә уңышлы гәүдәләндерә ала белү дә имам сөйләмендә зур әһәмияткә ия;

8) тагын бер сыйфат - сөйләмнең эмоциональлеге, хисле булуы. Имам мөнбәргә менеп сәгать буе борыны астына гына "мыгырданып" торса, аны тыңларга кыен булачак, ул бу очракта кешеләрнең игътибарын җәлеп итә алмаячак. "Үз борыныңа сөйләү" ысулы вәгазьне, әлбәттә, нәтиҗәле итә алмый. Шуңа күрә имам алдында берничә генә кеше утырса да, ул һәркемне аерым һәм тулаем җәмәгатьне инандырырлык дәрәҗәдә фикерләрен эмоциональ, хисле итеп җиткерә белергә тиеш. Тавышның төрле төсмерләре, кул хәрәкәтләре, башка мәгънәви ишарәләр, хәтта күз карашы да бу нисбәттә имамга ярдәм итә ала. Хисле сөйләм, шулай итеп, вәгазьне җанландырып җибәрә, аның сыйфатын арттыра;

9) инде билгеләп үтелгәнчә, мәчеткә төрле кеше җыела, алар арасында олы яшьтәге, начар ишетүче өлкәннәр дә була. Шуңа күрә имамның тавышы көчле, сөйләме исә анык, ышанычлы, яхшы дикцияле булу бик тә мөһим;

10) вәгазь сөйләү нәтиҗәсендә бирелгән белем-мәгълүматны тыңлаучылар истә калдырсыннар өчен имам рефрен ысулын кулланса, ягъни төп, иң кирәкле фикерләрне урынлы кабатласа яхшы була. Әмма, уйламыйча, максатсыз тәкърарлап торудан сакланырга кирәк;

11) имам сөйләмендә пауза (тыныш) ысулы да бик мөһим нәрсә булып санала. Аның максаты - билгеле бер фикергә басым ясау, игътибар юнәлтү; шулай ук тыңлаучыларны берара сөйләүдән ял иттереп, әйтелгән фикерне күңелләрендә ныгытып кую;

12) сөйләгәндә имам грамматик хаталардан сакланырга тиеш. Хаталы сөйләү вәгазьнең кыйммәтен киметә.

***

Шулай итеп, дин әһеле сөйләме, дөньяви сөйләм кагыйдәләренә нигезләнсә дә, шактый күп үзенчәлекләргә ия. Моны күренекле имамнарыбыз да, Ризаэддин Фәхреддин, Каюм Насыйри, Җиһангир Абызгилдин кебек каләм ияләре дә үз хезмәтләрендә исбатлый.

Имам вазифасы - кешеләр йөрәкләренә изгелек, игелек орлыклары чәчү. Ә бу турыдан-туры сүз сәнгате, сөйләм осталыгы белән бәйле. Коръәндә искә алынган хикмәт иясе Локман Хәким билгеләп үткәнчә, кешеләрнең йөрәге ул - чәчүлек урыныдыр һәм анда фәкать яхшы сүзләр һәм фикерләр "чәчәргә" кирәк; шуларның кайберләре булса да шытым, иншә Аллаһ, бирәчәк...

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе директоры**

# Г.ИСХАКЫЙ һәм Г.ТУКАЙ әсәрләрендә гаилә тәрбиясе проблемалары

*(Дәвамы. Башы газетабызның 22 февраль санында.)*

Гаяз Исхакый "Көз" (1923-1938) повестенда да төп героинялары Гөлсем һәм Нәфисә образлары аша ислам дине кануннарына нигезләнгән гаилә тәрбиясенең җәмгыяви тәрбиядән өстенрәк булуын дәлилли. Яшьтән үк дини тәрбия алган Нәфисә нык иманлы, көчле рухлы, аң-белемле,үз бәхете өчен көрәшергә сәләтле шәхес булып формалаша. Ә Гөлсем исә рус даирәсендә тәрбияләнеп, дини тәрбиядән мәхрүм була. Ул үз бәхете өчен көрәшергә сәләтсез. Дини һәм милли тәрбиядән мәхрүм булган Гөлсемнең ачы язмышка дучар булуын сурәтләп, Г.Исхакый ислам диненең татар халкын, аның телен, гореф-гадәтләрен саклап калучы бердәнбер фактор икәнен дәлилли. "Әүвәл әхлак бозыла, икенче, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә", - дигән сүзләренә тугры калып, татар халкын халык итә торган дин, тел, моң, гореф-гадәтләрне саклап калуның зарурилыгын исбатлый. Боларны саклап калуда хатын-кыз, тәрбияче буларак, иң зур роль уйнавын ассызыклый.

Гаяз Исхакый традицияләре дәвам ителеп язылган Габдулла Тукай шигырьләрендә дә татар-мөселман көнкүреше, гаилә тормышы ислам дине йолалары белән үрелеп бирелгән. Билгеле булганча, мөселман гаиләсендә бала ислам дине нигезләре белән кече яшьтән үк таныша башлый. Тукай да үзенең бала чагындагы иң беренче хәтирәләрен "Туган авылым" шигырендә түбәндәгечә сурәтли:

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

"Ана илә бала" шигырендә кызыксынучан, көр күңелле сабый баланың әнкәсенә биргән сораулары бу дөньяның хуҗасы кем булуын белү белән бәйле:

Җавап бирсәң икән, әнкәй, минем әйткән сөальләргә,
Гаҗәпләндем бу дөньяга вә анда барча хәлләргә:
Ничек булган, ничек үскән бу хисапсыз дәү-дәү урманнар?
Бу һәйбәт ямь-яшел кырлар каян килгән вә булганнар?
- Яраткан, әйләгән мәүҗит боларның барчасын Тәңрең,
Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән, бәгърем.

Шигырьдә ана һәм бала арасындагы җылы мөнәсәбәт, ананың баласына хакыйкатьне күркәм рәвештә җиткерүе

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Вакыф төшенчәсе һәм аның асылы

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

## Күчемсез милек вакыфы

Мөселман хокукы буенча, күчемсез милек белән дә вакыф эшләргә була. Аларга, мәсәлән, шундый мөлкәтләр керә: җир, йорт, кибет, кое һ. б. Һәм дә бу мөлкәтне, бу милек файда, табыш китерә торган вакытка кадәр вакыфка бирергә була. Күчемсез милекнең канунилыгы Коръәндә һәм Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) Сөннәтендә дә әйтелгән. Бу турыда сәхабәләр (Аллаһ алардан разый булса иде!) тормышы да дәлилли. Алда без Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) сәхабәсе Җәбирнең (Аллаһ аңардан разый булса иде!) сүзләрен китергән идек инде: "Вакыф эшләргә чак кына булса да мөмкинлеге булган очракта, аны эшләми калган бер генә сәхабә дә юк иде". Ә алар, билгеле булган, йортлар, җирләр, коелар белән вакыф эшләгәннәр.

## Күчемле милек вакыфы

Күчемсез милек вакыфы булган кебек үк, күчемле милек вакыфы да бар. Алар арасыннан шундыйларын санап китәргә мөмкин: машиналар, мал-туарлар, корал, урын-җир кирәк-яраклары, савыт-саба, файдалы әдәбият һ. б. күчемле милек белән эшләнгән вакыфлар.

*Андый вакыфлар булуының канунилыгы файдасына Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) хәдисләре дәлил һәм аргумент булып тора. Аларның берсендә шулай дип әйтелә: "Кем дә булса Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның вәгъдәсенә (ихлас кылынган һәрбер игелекле гамәл өчен аның рәхмәтләренә, савапларга ирешүгә) ышанып һәм үзенең атын вакыф итсә, аның (бу атның) ашатылган-эчертелгән булуы һәм тирес-сидеге дә бу кеше файдасына Хисап көнендә Үлчәүгә куелыр" (әл-Бохари, 2698).*

مَنْ احْتَبَسَ فَرَسًا فِي سَبِيلِ اللَّهِ إِيمَانًا بِاللَّهِ وَتَصْدِيقًا بِوَعْدِهِ فَإِنَّ شِبَعَهُ وَرِيَّهُ وَرَوْثَهُ وَبَوْلَهُ فِي مِيزَانِهِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ

*"Сахих әл-Бохари"дагы икенче бер хәдистә Аллаһ Рәсүленең (сгв) шулай дип әйтүе китерелә: "Сез Халидны (ул зәкят түләми дип) кыерсытасыз, ул үзенең көбәсе, хәрби кием һәм коралларын вакыф итте бит" (әл-Бохари, 1399).*

## Вакыфның формулировкасы

1) Нәрсәне дә булса вакыф итәргә теләгән кеше, ул бу вакыфны нәкъ менә үзе эшләгәне турында төп-төгәл итеп әйтергә тиеш. Ә телсез кешенең вакыф эшләү теләген язма рәвештә белдерүе лазем.

2) Аның сүзләре вакыт буенча чикләү мәгънәсендә нindidер вакыт аралыгы күрсәтелүдә булмаска тиеш. Мәсәлән, вакыфны оештыручы: "Мин үземнең йортымны дини гыйлемнәр өйрәнүчеләр (мөтәгаллимнәр) өчен бер елга вакыф итеп бирәм", - дип әйтә икән, андый вакыф чын вакыф булып санала алмый. Чөнки вакыф ниндидер бер вакыт аралыгы белән чикләнә алмый, ул даими булырга тиеш. Ләкин бу очракта да искәрмәләр бар. Мәсәлән, андыйлар исәбенә мәчетләрне, гыйбадәт кылу бүлмәләрен, зират өчен җирләрне һ. б. кертергә була. Әгәр кем дә булса, үз җирен бер елга мәчет төзү өчен вакыф итеп бирәм дип әйткән икән, бу вакыфка исәпләнә, ә вакыт белән чикләнү юкка чыгарыла.

3) Вакыф турындагы билгеләмәдә, мәҗбүри рәвештә, аның нинди максатларда тапшырылуы күрсәтелергә тиеш. Әгәр нәрсәне дә булса вакыф итәм дип әйтелеп, аның нинди максатларда вакыф ителүе әйтелми икән, бу вакыфның максатлары, ягъни бу мөлкәтне ничек итеп һәм нәрсәләр өчен файдаланырга тиешлеге ачык булмау сәбәпле, андый вакыф чын булып саналмый.


4) Вакыф нинди дә булса бер шарт, вакыйга һ. б. белән бәйле рәвештә бирелмәскә тиеш. Мәсәлән, әгәр кем дә булса берәү: "Әгәр дә миңа Әхмәд килсә, мин үз йортымны мохтаҗлар өчен вакыф итәм", - дип әйтә икән, мондый вакыф та чын булып саналмый.

5) Кире кайтару мөмкинлегенең юклыгы. Вакыфның билгеләмәсе буенча, анда, сату-алулар вакытында куелгандагы кебек, килешүдән баш тарту шартлары куела алмый. Мәсәлән, сату-алу вакытында, анда катнашучылар, өч көн эчендә, алар килешү буенча килгән бу карарларыннан баш тарту турында шарт куя алалар, ә вакыф очрагында мондый шарт куела алмый. Ягъни, әгәр дә сатып алучы, сатып алу килешүендә өч көн эчендә сатып алынган товардан баш тарту турында әйткән булса, бу товар аны кай ягы белән булса да канәгатьләндермәсә, ул шул вакыт эчендә бу товарны илтеп биреп, акчасын кире кайтаруны таләп итә ала. Һәм шул ук вакытта, сатып җибәрүче дә андый хокуктан, әлбәттә, баш тартмаячак. Ә вакыфта исә андый шарт мөмкин түгел! Андый шартларның булуы вакыф таләпләренә каршы килә һәм ул вакыф булып санала алмый.

Аллаһы Тәгалә барчабызга да Үз юлында вакыф эшләр өчен мөмкинлекләр, ә иң мөһиме - нинди дә булса бер мөлкәтебезне вакыф итәр өчен теләк-ниятләр бүләк итсә иде!

**Гамир ГЫЙБАДУЛЛИН,**
**Татарстан Республикасы Вакыф фонды генераль директоры;**
**Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ,**
**Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые, Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе**

# Нәфис чәчәк сулмасын иде



***АЗАЛИЯ - Илфат һәм Алсу гаиләсендә көтеп алынган икенче бала. Абыйсы Инсафка (аңа хәзер дүрт яшь) сеңел кирәк бит инде! Тик язмыш бәләкәчкә нинди сынаулар әзерләгәнен әти-әни белми әле: кызчык (ул чынлап та бик кечкенә була) җитлекмичә туа...***

Якыннары нарасыйга бер яшь тулганчы аның нәкъ башка балалар кебек үсәсенә өметләнә, тик өметләр генә акланмый шул! Киресенчә, табиблар куйган берсеннән-берсе җитди диагнозлар гаиләне борчуга сала. Менә алар:

Последствие органической патологии головного мозга с синдромом спастического тетрапареза, задержки развития высших функций, эпилепсия, инфантильные спазмы ЧАЗН. Гиперкинетическая форма ДЦП. Врождённый гипотиреоз лёгкой степени. Недоношенность IV степени (28 недель).

Хәзерге вакытта башын тотмый, әйләнеп ятмый, утырмый, күзләре күрми, көненә утызлап тапкыр өянәк (эпилепсия, падучая болезнь) була.

Азалиягә 1 яшь тә 4 ай, ләкин аның үсеше тоткарлана.

Ничек дәваларга, кемгә мөрәҗәгать итәргә, каян акча табарга? Дөньяга аваз салган нарасыйны һич кенә дә салкын җир куенына тапшырасы килми.

Кызчыкның Наилә әбисе күптән намазда. Ул Коръән сүрәләрен гарәпчә укый. Намаз саен Аллаһтан оныгына саулык-сәламәтлек сорый. Бабасы Илфир инде гүр иясе. Әти-әнисе Азалиянең күзләрен тутырып якты дөньяга багуын, башын югары тотып очуын-сикерүен күрергә, чишмә челтерәгәндәй нәфис тавыш белән көлүен ишетергә тели.

Табиблар, көчле белгечләр дәвалаганда, уңай үзгәрешләр булачагына өметләндерә. Тик моның өчен күп акчалар кирәк. Авылда яшәүче гаиләнең финанс мөмкинлекләре гаять тә чикле. Әнисе кызчыгын карый, әбисе өлкән яшьтә, группада. Гаиләнең төп туйдыручысы - этиләре Илфат.

Алсуның әти-әнисе дә гап-гади авыл кешеләре. Ярдәм итәрдәй бай туганнар да, спонсорлар да юк. Бөтен өметләре - мәрхәмәтле халыкның ярдәме. Өянәк (эпилепсия) еш кабатлану сәбәпле, Украинага алмыйлар. Франциядәге махсус белгечләргә күрсәтү таләп ителә. Аңарчы түләүле томография үтәсе бар. (Бер көне дә кадерле, түләүсезе чират буенча апрельдә генә).

Баланы утыртып кую өчен махсус кресло кирәк, анысы да кыйммәт (35 мең сум тора).

Дин кардәшләр, милләттәшләр, күңелендә мәрхәмәт хисе булган һәркем - зинһар ярдәм итегез, сулмасын иде нәфис чәчәк!

Акчаны түбәндә китереләчәк махсус счётка күчерергә мөмкин.

Алдан ук Хәйретдиновлар гаиләсе һәммә ярдәм иткән кешегә рәхмәтләрен җиткерә, кызларының сезнең ярдәм белән терелүенә өметләнә. Счёт номерлары:

**СБЕР. КНИЖКА СБЕРБАНКА**
***Получатель Хайрутдинова Алсу Фоатовна.***
***Волго-Вятский банк Сбербанка НА г. Нижний Новгород.***
***БИК 049205603***
***ИНН 7707083893***
***КПП 163502001***
***Корреспондентский счёт 30101810600000000603***
***Расчётный счёт 47422810362109999001***
***Номер счёта: 42307810662102906196/48***

# Г.ИСХАКЫЙ һәм Г.ТУКАЙ
## әсәрләрендә гаилә тәрбиясе проблемалары

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

укучыда соклану уята. Әлеге күренеш исламда бала тәрбиясенең матур бер үрнәген тасвирлый.

"Таян Аллага" шигырендә Тукай, гөнаһсыз яшь балага мөрәҗәгать итеп, аны мәрхәмәтле Аллага таянырга чакыра:

Йа Ходай, күрсәт, диген,
ошбу җиһанда якты юл;
Ул - рәхимле; әткәңәнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Шигырьдәге дога мотивы да игътибарга лаек:

Кыйл дога, ихлас белән тезләндә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!

Гыйбадәтнең бер төре буларак дога мөселманнар тормышында аерым бер урын били. Шатлык килгәндә дә, кайгы килгәндә дә мөселманнар һәрчак Аллага дога кылалар, аннан ярдәм сорыйлар.

"Ана догасы" шигырендә дә намаздан соң дога кылучы ана образы сурәтләнә:

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!
Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

Ана, баласы өчен борчылып, бары Алла гына ярдәм итә алуын таный һәм Аңа ялвара. Укучы күңелендә ана догасының кабул булачагына ышаныч туа, чөнки ул - ихлас күңелдән кылынган дога. Ислам дине тәгълиматыннан билгеле булганча, ананың баласына булган догасы, һичшиксез, кабул ителә.

**(Дәвамы бар.)**

# Котлыйбыз!

**Шушы көннәрдә Мамадыш районы Акман авылы хәзрәте МИСБАХ ГАТА улы һәм абыстае БИБИӘМИНӘ ТАЛИП кызы ГАТИННАРНЫҢ туган көннәре, Рәхмәт мәчете имамы ИСМӘГЫЙЛЬ МИННЕЯЗ улы ГАЯНОВНЫҢ 50 яшьлек юбилейлары.**

Хөрмәтлеләребез! Сезне гомер бәйрәмегез белән ихлас күңелебездән тәбрик итәбез. Без Сезне киң күңелле, миһербанлы, нык иманлы кешеләр булуыгыз өчен яратабыз. Сезгә күңел яктылыгы, җан җылысы тоеп, хикмәтләр белән эш итеп, муллыкта, тынычлыкта, саулыкта яшәргә, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп булсын.

*Гомерне бит еллар билгеләми,*
*Яшәү дәрте булсын күңелеңдә.*
*Сәламәтлек, бәхет-куанычлар*
*Юлдаш булсын Сезгә.*

***Барлык имамнар, абыстайлар, дин әһелләре исеменнән Мамадыш районы имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миннегалиев.***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 9 (178) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35392.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 28 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**